**СОВЕТ ТАТАРСКО - ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422634 с.Татар Янтык,
ул. Магазинная, д 31 а
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422634 Татарский Янтыгы авылы,
Кибет урамы, д 31а йорт
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

---

2020 елның 22 июне                                        18 номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге советы дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларны билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2007 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 105 статьясындагы 1 өлеше белән, “Татар Янтыгы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясына таянып, Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге Советына дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында, кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга(халыкка җиткерергә).

**Башлык –ТР Лаеш муниципаль**
**Районы Татар Янтыгы авыл җирлеге**
**Советы рәисе                                        Р.М.Шамеев**